Республика Татарстан
Зеленодольский муниципальный район
**Глава Большекургузинского сельского поселения**
Мирная ул., 41 с.Б.Кургузи, 422525
Тел:2-80-29
E-mail: Bkrg.Zel@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Зеленодол муниципаль районы
**Олы Карауҗа авыл җирлеге башлыгы**
Тынычлык ур., 41 О.Карауҗа ав., 422525
Тел:2-80-29
E-mail: Bkrg.Zel@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**КАРАР**

**27 август 2018 ел** **№12**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге территориясен планлаштыру һәм ызынлау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 14 ст. 1 ө. 20 п. нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 ст., Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге территориясен планлаштыру һәм ызынлау проекты буенча 2018 елның 15 октябренә 14.00 сәгатьтә, ТР, Яшел Үзән муниципаль районы, Олы Карауҗа авыл җирлеге, Күпер урамы, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан Олы Карауҗа авыл җирлеге администрациясе бинасында ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге территориясен планлаштыру һәм ызынлау проекты белән түбәндәге адрес буенча танышырга мөмкин: ТР, Яшел Үзән муниципаль районы, Олы Карауҗа авыл җирлеге, Олы Карауҗа авылы, Күпер урамы, 23.

3. Авыл җирлеге башкарма комитеты халык алдында тыңлаулар үткәрүне, Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге территориясен планлаштыру һәм ызынлау проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Олы Карауҗа авылы, Күпер урамы, 23 нче йорт (авыл җирлеге администрациясе бинасы), Олы Кульбаш авылы, Подгорная урамы, 26 нчы йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән; Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районының мәгълүмат сайтында урнаштырырга (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) Интернет челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) шулай ук «Яшел Үзән " газетасында да бастырып чыгарырга кирәк».

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Олы Карауҗа авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **М.Г.Шакиров**